МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

22.06.2020 г.Казань № 449

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2020 елның 14 июлендә 6757 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2016 елның 18 февралендәге 78 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күченүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2016 елның 18 февралендәге 78 номерлы "Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күченүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күченүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә

әгъзаларына башка җирлеккә күченеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына китерелгән үзгәрешләрне (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 16.10.2018 ел № 950, 07.05.2019 ел № 331, 16.11.2019 ел № 1037, 10.02.2020 ел № 82 боерыкларында кертелгән үзгәрешләр белән) расларга.

Министр Э.А. Зарипова

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин
итү һәм социаль яклау
министрлыгының
«22» 06 2020 № 449
боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2016 елның 18 февралендәге 78 номерлы "Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күченүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" боерыгы белән расланган
Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күченүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр

1.7 пункттагы дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба - министрлык) (http://mtsz.tatarstan.ru), халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең рәсми сайтында. Министрлыкның, халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең Интернет челтәрендәге рәсми сайтында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүматлар арасына әлеге Регламентның 1.6, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктлардагы дәүләт хезмәте турында белешмәләр кертелгән;»;

1.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (аларның реквизитлары һәм рәсми бастырып чыгару чыганаклары белән) «Интернет» челтәрендәге Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.»;

1.9 пунктта:

икенче абзацта «210-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен «2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законы (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон)» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «муниципаль районның (шәһәр округының) шәһәр яисә авыл җирлегендә төзелгән» сүзләрен «муниципаль районның шәһәр (авыл) җирлегендә яисә шәһәр округында төзелгән» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерык» сүзләрен «Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы «Халыкны эш белән тәэмин итүдә булышлык өлкәсендә дәүләт хезмәтләре алучының шәхси эш бланк формаларын раслау турында» боерыгы (алга таба - 19.02.2019 ел № 90н боерыгы)» сүзләренә алмаштырырга;

2.1 пунктның «Хезмәтне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында «Халыкны эш белән тәэмин итү турында Закон» сүзләрен «1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» Россия Федерациясе Законы (алга таба – Халыкны эш белән тәэмин итү турында Закон)» сүзләренә алмаштырырга;

2.2 пунктның «Хезмәтне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында «92н номерлы стандарт» сүзләрен «Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2013 елның 92н номерлы «Эшсез гражданнарга күчеп китүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка җирлеккә күчеп китүдә ярдәм итү буенча дәүләт хезмәтенең федераль дәүләт стандартын раслау турында» боерыгы белән расланган Эшсез гражданнарга күчеп китүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка җирлеккә күчеп китүдә ярдәм итү буенча дәүләт хезмәтенең федераль дәүләт стандарты (алга таба - 92н номерлы стандарт)» сүзләренә алмаштырырга;

2.4 пунктның «Хезмәт күрсәтүне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында «2015 елның 16 ноябрендәге 872н номерлы боерыкка» сүзләрен «Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 16 ноябрендәге 872н номерлы «Хезмәт белән тәэмин итү органнары һәм федераль медик-социаль экспертиза учреждениеләре арасында белешмәләр алмашу тәртибен, формасын һәм срокларын раслау турында» боерыгына (алга таба - 2015 елның 16 ноябрендәге 872н номерлы боерык)» сүзләренә алмаштырырга, «515 номерлы Тәртип» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 15 июнендәге 506-15 номерлы «Эшсез гражданнарга күчеп китүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка җирлеккә күчеп китүдә ярдәм итү буенча дәүләт хезмәтенең федераль дәүләт стандартын раслау турында» карары белән расланган Эшсез гражданнарга күчеп китүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка җирлеккә күчеп китүдә финанс ярдәм бирү тәртибе (алга таба - 515 номерлы Тәртип)» сүзләренә алмаштырырга;

2.5 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасында «63-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен «2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы «Электрон имза турында» Федераль закон (алга таба - 63-ФЗ номерлы Федераль закон)» сүзләренә алмаштырырга;

2.6 пунктта:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына карата таләп атамасы» графасында «башка оешмалар» сүзләрен «дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасында «486н номерлы боерыкка» сүзләрен «Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2017 елның 13 июнендәге 486н номерлы «Федераль дәүләт медик-социаль экспертиза оешмалары тарафыннан бирелә торган инвалидны реабилитацияләү яки реабилитацияләүнең индивидуаль программасын, инвалид баланы реабилитацияләү яки реабилитацияләүнең индивидуаль программасын һәм аларның формаларын эшләү һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» боерыкка (алга таба - 486н номерлы боерык)» сүзләренә алмаштырырга;

2.12 пунктның «Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгеләүче норматив хокукый акт» графасында «601 номерлы Указ» сүзләрен «Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» Указы (алга таба - 601 номерлы Указ)» сүзләренә алмаштырырга;

2.9 пунктның «Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгеләүче норматив хокукый акт» графасында «1032-1 номерлы Халыкны эш белән тәэмин итү турында Закон» сүзләрен «Халыкны эш белән тәэмин итү турында Закон» сүзләренә алмаштырырга;

2.15 пункттагы «Дәүләт хезмәтен яисә таләпне билгеләүче норматив хокукый акт» графасында «ТР МК 880 номерлы карары белән расланган Тәртип» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 декабрендәге 880 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча административ регламентлар эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында» карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча административ регламентлар эшләү тәртибе (алга таба – ТР МК 880 номерлы карары белән расланган Тәртип)» сүзләренә алмаштырырга;

8 нче кушымтада «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» Россия Федерациясе Законына таянып» сүзләрен «1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» Россия Федерациясе Законына таянып» сүзләренә алмаштырырга;

9 нчы кушымтада «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» Россия Федерациясе Законына таянып» сүзләрен «1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» Россия Федерациясе Законына таянып» сүзләренә алмаштырырга.